Туган телем - иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем...

# Кумәк көч

ГОМУМИ РАЙОН
ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 12 (10704)
Чәршәмбе,
22 март 2017 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1)2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ, ИСКЕ КУЛАТКЫ ЭШЧЕЛӘР БИСТӘСЕ, ПИОНЕРСКАЯ УРАМЫ, 30)

## XVI нчы Кулаткы укулары

# Нәрсә җитә Ана булуга



15 – 16 март көннәрендә Иске Кулаткы бистәсенең "Җәмигъ" мәчетендә "Ана булу – бөек исем. Нәрсә җитә ана булуга" дип исемләнгән XVI нчы Кулаткы укулары үтте. Әлеге ф әнни – гамәли конференциядә "Бөтен күрке Ана булуда" дип аталган "түгәрәк өстәл" утырышы да оештырылган иде. Бу әһәмиятле чарада дин әһелләре, Татарстан төбәгеннән кайткан зыялылар, галимнәр катнаштылар.

Беренче көнне Иске Кулаткы районы мәчетләрендә эшләүче абыстайлар, мөгаллимәләр һәм мөгаллимә ярдәмчеләре тест формасында имтиханнар бирделәр. Комиссиянең рәисе Җәлил хәзрәт Фазлыев булды. Тестларны уңышлы биргән апаларга Үзәкләштерелгән дини оешма – ТР мөселманнары Диния нәзарәте Мөселман дини оешмасы – урта һөнәри белем бирү учреждениесе "Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе" сертификатларын комиссия әгъзасы Э.Ә. Ганеев тантаналы төстә тапшырды. Әлеге сертификатлар абыстайларга үз мәхәлләсендә мәҗлесләр үткәрергә, вафат булганнарны барлык йолаларын дөрес үтәп, соңгы юлга озатырга бурычлы итте, ә мөгаллимәләргә шәкертләргә дини гыйлем укытырга хокук бирде. Биредә шулай ук "Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе" мөгаллимәләре Зөлфия абыстай Гарифуллина һәм Венера абыстай Заһретдинова мәетне нинди кагыйдәләр башкарып җирләү буенча абыстайларга остаханә күрсәттеләр, сорауларына җаваплар кайтардылар. Безнең йолалардан тик вафат булган өстенә җавапнәма тегеп кую гына дөрес башкарылмаганы ачыкланды. Шулай ук гүр сәдакасын бирү дә шарт түгел диелде.

Икенче көнне фәнни – гамәли конференция шул ук дин әһелләренең катнашында дәвам итте.

Төп мәсьәлә - "Ана булу – бөек исем. Нәрсә җитә Ана булуга" темасы һәр чыгышта кызыл тасма кебек җәелеп барды.Барлык чыгыш ясаучы ананың бөеклеген, вазифасын, бурычларын күрсәтергә, аңлатырга тырышты. Татарстан республикасы мөселманнар казые Җәлил хәзрәт Фазлыев бик күп әдәпле , акыллы мисалларда ананың бурычларын аңлатты.

Кулаткы укуларында Губернатор киңәшчесе, өлкә администрациясе каршындагы гаилә һәм демография мәсьәләләре буенча идарә начальнигы О.В. Желтова катнашты. Ул үзе дә дүрт бала анасы икән. Үзенең чыгышында әлеге теманың бик актуаль булуын ассызыклады.

"Өлкә Губернаторы С.И. Морозов бу теманы көнүзәк мәсьәлә итеп куя һәм эшлекле чаралар оештыра. Гаилә һәм балалар - безнең иң зур байлыгыбыз, без аларны сакларга тиешбез," - диде ул чыгышында. Аннары район ЗАГС бүлеге белән берлектә чирек гасыр бергә тату яшәп, үз балаларын гына түгел асрауга да балалар алып үрнәк яшәүче Тумашевлар гаиләсенә Губернатор исеменнән Рәхмәт хаты һәм бүләк тапшырды. Фәнни – гамәли конференцияне район Башлыгы Э.Ә. Ганеев һәрвакыттагыча оештырды, алып барды һәм йомгаклау сүзе белән дә чыкты. Биредә бик күп актуаль проблемалар күтәрелде, файдалы сүзләр әйтелде.

**Майзә МАСИЕВА.**

### Хөрмәтле мәдәният хезмәткәрләре, мәдәният тармагы ветераннары!

Әлеге бәйрәм гаять бай әдәби мирасыбызны популярлаштыруга, җәмгыятебезнең рухи үсешенә үзеннән бәяләп бетергесез өлеш кертеп килүче талант ияләрен берләштерә. Мәдәният һәм театр хезмәткәрләре көне җәмгыятебез тормышының барлык катламнарына кагыла. Әлеге бәйрәм театрлар, музей, китапханә, сәнгать мәктәпләре хезмәткәрләренең генә түгел, мәдәният, масса-күләм мәгълүмат чаралары, тамашачылар, үзешчән сәнгать артистлары, гомумән, иҗатны, мәдәни кыйммәтләрне үз итүче һәркем өчен бәйрәм.

Барчагызны да шушы күркәм бәйрәм белән кайнар тәбрик итеп, районыбыз халкының мәдәниятен бергәләп югары дәрәҗәләргә күтәрербез, дип ышанабыз һәм барчагызга да уңышлар телибез.

**Э. Ә. ГАНЕЕВ,**
**Иске Кулаткы районы Башлыгы. "Бердәм Россия" партиясенең урындагы политсовет Секретаре.**

**И. А. АБЛЯЗОВ,**
**Иске Кулаткы районы администрациясе Башлыгы.**

### "Кумәк көч"кә алдан язылу дәвам итә. Хөрмәтле газета укучыларыбыз!

**Иске Кулаткы районының почта бүлекчәләрендә 2017 елның икенче ярты еллыгына (июль-декабрь) газеталарга алдан язылу дәвам итә. Сез бүгеннән үк почта бүлекчәләренә, хат ташучыларга мөрәҗәгать итеп, «Кумәк көч» район газетасына иске бәяләр буенча, ягъни 349 сум 26 тиеннән, язылып куя аласыз, аннары хаклар күтәреләчәк.**

### Ярминкә барчагызны да көтә!

**25 мартта һәм 1 апрельдә**
**иртәнге 8.00 сәгатьтә**

**Иске Кулаткы эшчеләр бистәсендәге "Агропромпаркта" (базар урынында) район авыл хуҗалыгы ярминкәсе оештырыла. Ярминкәдә авыл хуҗалыгы товарларын житештерүчеләр төрле ассортиментта үзләренең продукцияләрен тәкъдим итәчәкләр. Салам, печән, төрле – төрле бөртекләр, комбиазык ит, көнбагыш мае һәм яшелчәләр сатуга чыгарылачак. Шулай ук райондашларыбызны шәхси хуҗалыкларында житештергән продукцияләрен реализацияләргә көтеп калабыз.**

**Ярминкәгә рәхим итегез!**

| ПӘНҖЕШӘМБЕ (23.03.) | ҖОМГА (24.03.) | ШИМБӘ (25.03.) | ЯКШӘМБЕ (26.03.) | ДҮШӘМБЕ (27.03.) | СИШӘМБЕ (28.03.) | ЧӘРШӘМБЕ (29.03.) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| + 5 | + 6 | + 6 | + 6 | + 5 | + 3 | + 11 |
| - 1 | 0 | 0 | + 2 | + 1 | - 3 | + 3 |

# Гражданнар кабул ителде

№ 12, 22 март 2017 åё.

## ЯҢАЛЫКЛАР



Владимир Путин Иҗтимагый палата составын раслады. Әлеге указ нигезендә расланган Иҗтимагый палата әгъзаларына, Россия субъектларының Иҗтимагый палаталарыннан вәкил итеп җибәрелгән Россия федерациясе Иҗтимагый палатасы вәкилләре белән берлектә, Иҗтимагый палатаны тулы составта формалаштыру эшенә керешергә тәкъдим итәргә, диелә дәүләт башлыгы указында.

● ● ●

Россия Президенты Владимир Путин Алма-Атада узган XXVIII Бөтендөнья кышкы универсиадада уңышлы чыгыш ясаган ил спортчыларына рәхмәт белдерде. Бүләкләү турындагы боерык хокукый мәгълүмат рәсми интернет -порталында бастырылды.

● ● ●

Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин мәдәният һәм сәнгать Советы һәм рус теле буенча Советның уртак утырышы нәтиҗәләре буенча йөкләмәләр исемлеген раслады.

● ● ●

Дөньяда иң эре азык-төлек җитештерүче булу өчен Россиянең потенциалы бар, дип белдергән Россия Президенты Владимир Путин. "Безнең җитештерүчеләр эчке базарны сыйфатлы азык белән тулысынча тәэмин итә алачагына ышанам: дөньяда иң эре азык-төлек җитештерүче булу өчен Россиянең потенциалы бар. Бу киң күләмле, әмма реаль бурыч, иң мөһиме куелган бурычка эзлекле хәрәкәт итү", - диде.

● ● ●

Федераль һәм башкала хакимиятләренә Мәскәүнең Горький исемендәге Әдәби институты базасында милли әдәбиятлар Йорты булдыру мәсьәләсе йөкләнде.



20 марттан Ульяновск өлкәсендә язгы төзекләндерү эшләре старт алды. Әлеге мәсьәлә Губернатор С.И. Морозов җитәкчелегендә үткән чираттагы аппарат киңәшмәсендә каралды. 2017 елда төзекләндерүгә өлкә бюджетыннан 314 миллион сум акча юнәлтеләчәк.

● ● ●

Ульяновск өлкәсендә эшләүче әниләргә өстәмә ял көннәре биреләчәк. Әлеге йөкләмәне аппарат утырышында Губернатор С.И. Морозов бирде. Гаилә җәмәгатьчелеге дә яңалыкны хуплады. Ял көннәрен 19 январь (Ульяновск өлкәсенең барлыкка килүе), 1 июнь (Халыкара балаларны яклау көне), 8 июль (Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне), 1 сентябрь ( Белем көне) һәм 12 сентябрь (Гаиләдә аралашу көне)көннәрендә файдаланырга мөмкин булачак.

● ● ●

Регионда Бөтендөнья туберкулезга каршы көрәш көне кысаларында төрле профилактик чаралар үтәчәк. Әлеге чаралар Губернатор С.И. Морозов йөкләмәсе буенча 30 мартка кадәр дәвам итәчәк.

● ● ●

Губернатор С.И. Морозов һәм "Бердәм Россия" партиясенең өлкә бүлекчәсе инициативалары белән 21-22 март көннәрендә өлкәдә "Интернетта информацион куркынычсызлык" мәсьәләләре буенча регионара конференция оештырылачак.



15 мартта Иске Кулаткы районы "Бердәм Россия" партиясенең җирле бүлекчәсендә Иске Кулаткы шәһәр поселениесе депутатлары Сания Фәритовна Нугаева һәм Нариман Үмәрович Аблязов Иске Кулаткы авыл территорияләрен үстерү идарәсе начальнигы Ирфан Камилевич Аделов белән берлектә гражданнарны кабул иттеләр. Кабул ителүдә ике гражданның сораулары каралды. Аларның берсе – Иске Кулаткы эшчеләр поселогының Коммунальная урамын төзекләндерү, икенчесе - Пионерская урамына җәмәгать туалеты төзү кирәклеге турында иде.

Депутатлар тарафыннан бу ике мөрәҗәгать тә контрольгә алынды.

**Оксана Ямалетдинова, "Бердәм Россия" партиясе җирле бүлекчәсенең гражданнарны кабул итү буенча белгеч.**

### «ГОРЯЧАЯ ЛИНИЯ»

24.03.2017 г. Государственное учреждение - Управление Пенсионного фонда в Старокулаткинском районе проводит День бесплатной юридической помощи по вопросам входящим в компетенцию органов ПФР.

Ждем ваших звонков по телефону: 2-28-55.

## В Ульяновской области началась продажа авиабилетов по летним туристическим направлениям

**Полёты будут осуществляться из международного аэропорта «Ульяновск - Восточный».**

По информации специалистов Министерства промышленности, строительства, ЖКК и транспорта, ежегодно наблюдается стабильный спрос на летние туристические направления.



«В 2017 году мы продолжим осуществлять транспортное обслуживание пассажиров нашего региона по основным востребованным направлениям, в том числе в Симферополь, Сочи, Анапу. Также в этом году возобновляется авиасообщение с Турцией», - сказал директор Департамент транспорта Министерства промышленности, строительства, ЖКК и транспорта Олег Заварзин.

По его словам, в настоящее время начались продажи билетов по маршруту Ульяновск – Анталия (Турция). Полёты будет осуществлять авиакомпания Уральские авиалинии на воздушном судне Airbus A321 (220 мест),

**2 раза в неделю, по средам и воскресеньям. Начало рейсов с 25 апреля по 10 октября 2017 года.**

Также авиакомпания «КрасАвиа» планирует начать выполнение регулярных авиарейсов по маршруту «Ульяновск – Сочи» самолёте Як-42 (120 мест) по понедельникам. Период выполнения полётов с 19 июня по 11 сентября 2017 года.

Напомним, с 4 июня начинаются авиаперевозки в Симферополь. Полёты будут выполняться авиакомпанией Red Wings один раз в неделю по воскресеньям. Комфортабельные самолеты Ту-204 в компоновке 210 кресел будут летать из аэропорта «Ульяновск-Восточный» в летний период с 4 июня по 22 октября.

Для обеспечения туристических поездок ульяновцев на курорты Анапы с 1 июня начинают курсировать сезонные поезда дальнего следования «Ульяновск – Анапа».

**Как отмечают специалисты, активно развиваются и межрегиональные перевозки.** Так, авиакомпания «Руслайн» планирует начать выполнение регулярных авиарейсов по маршруту Ульяновск – Санкт-Петербург на воздушном судне CRJ-200 (50 мест), по вторникам и субботам. Начало полётов с 23.05.2017. Кроме того, возобновлены полёты по региональным направлениям – в Уфу и Нижний Новгород.

«В Нижний Новгород летаю часто по работе. Теперь добираться стало гораздо быстрее и комфортнее. Время в полёте чуть больше часа. Полёты выполняются на удобном самолёте бизнес-класса», - пассажир авиарейса «Ульяновск-Нижний Новгород» Алексей Баданин.

## В Ульяновской области восстановлены авиарейсы в Уфу

Полёты выполняются три раза в неделю из международного аэропорта «Ульяновск-Восточный».

«В 2017 году Росавиацией принято решение о продлении федерального проекта субсидирования региональных авиарейсов, в том числе в Приволжском федеральном округе. В программу включены маршруты «Ульяновск – Нижний Новгород» и «Ульяновск – Уфа». Мы и в дальнейшем планируем продолжать развитие авиаперевозок между регионами», - рассказал директор департамента транспорта Министерства промышленности, строительства, ЖКК и транспорта Олег Заварзин.

Полёты по данным направлениям выполняются авиакомпанией

Авиа Менеджмент Груп на восьмиместных самолетах бизнес - класса

Pilatus PC-12 в понедельник, среду и пятницу.

Напомним, в 2016 году также осуществлялись перелёты по данным направлениям перевезено 3042 пассажира, в том числе: 1078 пассажиров по маршруту «Ульяновск – Уфа», 1964 пассажира по маршруту «Ульяновск – Нижний Новгород».

**Для справки**

Расписание полётов:

по маршруту Нижний Новгород – Ульяновск: прилёт в Ульяновск – в 16.20 ч., вылет из Ульяновска – 17.15 ч., по маршруту Уфа – Ульяновск: прилёт в Ульяновск – в 17.00 ч., вылет из Ульяновска – 18.10 ч. Время ульяновское.

Авиабилеты продаются во всех кассах Ульяновской области.

### Вниманию сельхозтоваропроизводителей!

Вы сможете реализовать излишки произведенной сельскохозяйственной продукции на торговой площадке постоянно действующей ярмарки-выставки, которая расположена в Заволжском районе Ульяновска по адресу: ул. Наганова, 10 а.

Планируется, что площадка откроется 15 апреля. В скором времени аналогичная площадка заработает в Железнодорожном районе регионального центра на проспекте Гая, 100.

Торговля будет проходить в крытом павильоне, для продавцов будут созданы комфортные условия работы – наличие необходимого оборудования, в том числе, холодильного, единая форма одежды и оформление витрин. Место для торговли в течение первого полугодия предоставляется бесплатно.

**По всем интересующим вопросам обращаться:**

**89278033069 - Руслан Юмаев (исполнительный директор ТК "Нагановский")**

**89278123712 - Ольга Готальская (заместитель директора торговой базы "Гая, 100")**

**89272703758 - Павел Ляукин (исполнительный директор областного сельскохозяйственного кооператива).**

## Жители Ульяновской области теперь могут подать заявление на регистрацию брака в электронном виде на портале gosuslugi.ru

Всё большее количество государственных услуг граждане могут получить через Интернет. Услуга по подаче заявления на регистрацию брака для ульяновцев также стала доступна на ЕПГУ.

По словам руководителя Агентства ЗАГС Ульяновской области Жанны Назаровой, благодаря данной услуге парам не придется стоять в очереди, чтобы заявить о своем желании вступить в брак. Они могут сделать это в любое время суток через «Личный кабинет» одного из будущих супругов, заполнив электронную форму.

Зарегистрироваться в «Личном кабинете» и подтвердить свою учётную запись можно в любом ближайшем центре обслуживания пользователей портала госуслуг. Их порядка 180 в регионе.

«Почти половина жителей Ульяновской области уже зарегистрированы на портале госуслуг и имеют возможность оценить все преимущества его использования. Получение услуг в электронном виде не только экономит время, но и денежные средства. Так, оплачивая государственную пошлину через ЕПГУ, вы получаете скидку 30%», - рассказала директор ОГКУ «Правительство для граждан» Светлана Опенышева.

Как пояснили в Агентстве ЗАГС Ульяновской области, для получения услуги жених и невеста заполняют совместное заявление каждый в своем «Личном кабинете» на Едином портале госуслуг. Первый заявитель (жених или невеста) отправляет второму приглашение, внеся номер СНИЛС, дату рождения и адрес электронной почты. Второй заявитель получит ссылку на заявление, в которое необходимо будет внести свои данные и подтвердить место и дату регистрации. При этом заявление нужно заполнить в течение 24 часов.

Далее портал сформирует платёж. Оплата госпошлины также происходит онлайн. С учётом скидки стоимость госпошлины составляет 245 рублей. Напомним, размер госпошлины при личном обращении составляет – 350 рублей. После подтверждения факта оплаты необходимо отправить электронное заявление. Через некоторое время заявителям придёт сообщение с подтверждением о принятии электронного заявления.

Если на каком-либо этапе электронное заявление не пройдет проверку,

в «Личном кабинете» на портале госуслуг его статус будет изменен,

а в дополнительной информации - указана причина отказа.

По желанию пары государственная регистрация заключения брака может проводиться как в торжественной, так и в неторжественной обстановке.

Заявителю предоставляется возможность подать заявление на регистрацию заключения брака минимум за один, максимум за два месяца до торжественной даты, как в случае электронного заявления, так и при обращении в орган ЗАГС.

Кроме услуги по подаче заявления на регистрацию брака на портале можно выбрать удобное время для посещения отдела ЗАГС для регистрации рождения, усыновления или удочерения, а также регистрации смерти или расторжения брака.



# Батырлыгы - безгә үрнәк



Безнең татар халкы элек-электән батыр һәм горур булган. Аның җилкәсенә нинди генә авырлыклар төшсә дә, ул баш имәгән, йөзен югалтмаган, авырлыкларны җиңеп, матур, бәхетле киләчәккә омтылган. Икмәк үстергән, гаилә корган, балалар тәрбияләгән, кирәк вакытта кулына корал тотып, Ватан якларга дип, яу кырына чыгып киткән.

Бөек Ватан сугышы башлангач та, кечкенә генә гади Мосеевка авылыннан ике йөздән артык ир - егет озатыла, аларның күбесенә туган авылына кайту насыйп булмый. Авыл уртасында батырлар хөрмәтенә һәйкәл-обелиск салынган.

Мосеевка авылы тагын бер ягы белән данлыклы - биредә Советлар Союзы Герое Зәкәрья Сафетович Хәсәинов туган. Ул монда үскән, белем алган, гаилә корган, якты киләчәккә хыялланып яшәгән.



Зәкәрья Сафетович 1937 елның сентябрендә Кызыл Армиягә чакырылган. Хәрби хезмәтен тәгәлләп кайтуга, аңа яңадан туган илен дошманнардан яклап, сугышка китәргә туры килә. Японнарга каршы Хәсән күлендә сугыш кыйпылчыгы алган Зәкәрья аганың күкрәгендә инде ике "Кызыл Йолдыз", III нче дәрәҗәле "Дан" орденнары һәм "Сталинградны саклаган өчен" медале булган.

1944 елның 11 октябрь көне. Дошман тылы буенча 30 нчы кавалерия дивизиясенең 134 нче танк полкы рейдка чыга.

Техник сәбәпләр аркасында, старшина Хәсәиновның танкы полктан артта кала. Аны ремонтлап, танкистларга ашыгалар. Ләкин полкны куып җитим дигәндә генә, Венгриянең иң зур шәһәренең берсе булып саналган Дебреценга җитәррәк, Хайду-Сават шәһәрчеге районында аларга таба дошман танклары колоннасының каршы килүләрен күрәләр. Көчләр тигез булмый. Бер "тридцатичетверка"га каршы немецларның 18 "тигр"ы һәм "пантера"лары килә. Танк командиры Хәсәинов яшеренеп, бәрелешне кабул итмәкче була. Урман полосасына сыенып, экипаж сугышка әзерләнә. Беренче снаряд белән баштан килүче танк яндырыла, өченчесе белән икенчесенә ут каба. Шул арада фашистлар "тридцатичетверка"ны күреп алалар. Хәсәинов экипажы яңа позициягә күчеп, көрәшне дәвам итә. Тагын өч "пантера" дөрләп янарга тотына. Ике группага бүленеп, дошман урман полосасын фланглардан узарга тырыша. Хәсәинов шушы арада алтынчы танкны сафтан чыгара. Немец снаряды үзенең билгеләнгән урынына барып төшә. Турыдан-туры танкка эләгә. Шунда ук наводчик әле, ә Хәсәинов үзе яралана. Соңгы көчен җыеп, ул башнядан чыга, шуыша-шуыша якындагы фашист танкысына таба граната ыргыта. Көчле шартлау ишетелә. Хәсәинов икенче машинага сикерә, ләкин шул вакытта пулеметтан сиптергән утан ул һәлак була.

Ярдәмгә килгән совет танклары немецларның калган машиналарын тармар итәләр.

Зәкәрья Сафетович Хәсәиновның гомере 30 яшендә өзелә. Аның үле гәүдәсе Венгриянең Хайду - Сават торак пункты янында җирләнә.

Туганнарына, хатыны һәм балаларына аның соңгы сәламе булып "кара кәгазь" гене килә. Ә инде 1945 елның 24 мартын да Зәкәрья Сафетович Хәсәиновка Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Ялкын йөрәкле Зәкәрья Сафетович Хәсәиновның батырлыгын мәңгеләштерү максатыннан Мосеевка авылы уртасында 1965 елның 9 маенда обелиск ачыла. Анда геройның исеме ташка чокып язылган.

Күптән түгел генә Зәкәрья Сафетович Хәсәиновның тууына 103 ел тулды. Яшь буынны сугыш һәм хезмәт ветераннары үрнәгендә патриотик рухта тәрбияләү, Ватанга мәхәббәт, тугрылык арттыру – аеруча мөһим.

Советлар Союзы Герое З.С. Хәсәиновның сугышчан батырлыгы турында авылдашлары гына түгел, районыбыз халкы да онытмаска тиеш.

# 21 - март Бөтендөнья поэзия көне

### *Чын күңелдән котлыйбыз!!!*

Быел "Казан утлары" журналының санында, "Күмәк көч" район газетасының журналисты, Россия журналистлар Союзы әгъзасы Рөстәм Исмәгыйлович Арифуллинның "Җимерек баскыч", дип исемләнгән хикәясе басылып чыкты. Шушы уңайдан "Күмәк көч" редакциясе коллективы аны чын күңелдән тәбрик итә һәм киләчәктә дә иҗади уңышлар тели.

# Пожалысты

**(Юмореска)**



Хәзерге «теләсә нәрсә эшлә» дигән әрсез, демократик заманда халык арасында «Пожалысты» дигән сүз, көннән-көн киң кулланыш табып, үзенә зур абруй яулый бара.

Нәрсә эшләргә маташма, нинди генә гамәл кылма һәр җирдә сине «пожалысты» дигән сүз белән каршы алалар. Ирекле җәмгыятьтә торуыбызга шатланып туя алмыйбыз, кибет ачасың киләме, фермер хуҗалыгы ясыйсыңмы — берниндикиртә юк, һәрвакыт сиңа баш иеп «пожалысты» — диеп каршы алалар үзеңне. Теләгәнеңне яз, теләгәнеңне әйт — һәммәсенә дә яшел юл һәм «пожалысты, пожалысты» — дип кыстаулар яңгырый да, яңгырый гына.

Хезмәт урыныңда берәр низаг чыгып, «нәчәлеңнә» сүгеп ташлыйсыңмы — "пожалысты". Демократия чоры бит, пожалысты, акыр-бакыр, телең тик көтүченең чыбыркысы кебек озая барсын. Югарыда әйткән гамәлең өчен синең телеңне түгел, бары эш урыныңны кыскартулары гына ихтимал.

Әгәр озын телең аркасында эш урының кыскартыла икән, ул вакытта сине: «Пожалысты» — дип мәшгульлек үзәге (центр занятости населения) каршы ала. Монда сине: «Эш табырбыз, рәхим ит» — дип каршы алалар һәм соңыннан «всегда пожалысты» дигән эш урыны тәкъдим итәләр.

Инде бу «всегда пожалысты» дигән эш урынындагы «нәчәлне» сүгү генә түгел, аны биредә кыйнап ташласаң да эш урының гомердә дә кыскартылмый икән. Чөнки мәшгульлек үзәге үзенә шундый эш тәкъдим итә — биредә озын телеңне сузып, кыска хезмәт хакы алып, билеңне каттырып, бөкрәеңне чыгарып, хезмәт ит кенә, пожалысты.

Ай-һай бу «пожалысты» дигән сүз тормышның һәр почмагына, һәр ноктасына, бизнес, сәүдә, сату итүнең түренә үтеп керде бит, җәмагать. Мәсьәлән син хатын-кыз ди, бала табарга больницага барасың һәм сиңа анда: «Гинекологыбыз үзе дә бәби табарга шәһәргә китте, шәһәрдә баланы яхшы таптыралар икән, аның белән бергә бала табу зур бәхет, шәһәргә барыгыз пожалысты», — дип ягымлы гына озатып калалар үзеңне.

Инде хәзер кайда да эшләмәсәң дә, укып йөрмәсәң дә ярый, өйдә ятып торасыңмы, көмешкә куасыңмы — ул синең эш, теләсәң нишлә — "пожалысты".

Әгәр инде кәеф-сафа торгызу өчен көмешкә куа алмасаң, ул нәрсә безнең авылда «тыкрык Әсма»да сатыла, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ал да, эч "пожалысты"! Әгәр инде «тыкрык Әсма»ның көмешкәсенә тончыгып үлсәң, бу очракта бездә бизнес нокталары ачылды. Ул-бу була калса, авылда тимерче Таһир, мал туплау нияте белән зират челтәрләре ясый, комсыз Хафиз кәфен кибете ачты, ә кабер казучы гастарбайтерлар «зират йортында» ук яши… Гомумән әйткәндә, теге дөньяга да ишекләр ачык һәм «всегда пожалысты».

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**
**"Казан утлары".**





## Кадыйр Ахмеров иҗаты

### *Тик матурлык саклый дөньяны*

*Шау чәчәктәге гөлләрем,*
*Сузам сезгә кулларым.*
*Өзеп алырга, дип түгел,*
*Су сибәргә уйларым.*

*Сездән такыялар үреп,*
*Кияр идем яз-җәйдә.*
*Гомерләрегез өзүне*
*Гөнаһ дип саныйм. Җәлләм!*

*Шау чәчәктәге гөлләрем,*
*Сездәй күркәм уйларым.*
*Хуш исләрегезгә тиңләп,*
*Күңел күгем корамын.*

*Таҗ яфракларыгызга мин*
*Кунар идем чык булып.*
*Янар идем сезнең белән*
*Таң нурына кушылып.*

### *Атларым матурларым*

*"Атсыз егет-канатсыз кош"-*
*Мәңгелек хакыйкатьтер.*
*Гасырлар буе юккамы*
*"Тулпар"ны саклый хәтер.*

**Кушымта:**
*Әй, атларым,*
*малкайларым!*
*Акыллы, матурларым!*
*Бар телләрдә яңгырардай*
*Сез бит горур җырларым!*

*Муеннарыгызда - камыт,*
*Иңнәрегездә - ияр.*
*Җиңү яулаган егетләр:*
*"Атым-канатым!"- дияр.*
**Кушымта:**
*Әй атларым,*
*малкайларым!*
*Акыллы матурларым!*
*Бар телләрдә*
*яңгырардай*
*Сез бит горур җырларым!*

*Сез,атларым,*
*дусларымның*
*Иң эшчән, җитезләре!*
*Тарихыбыз юлларында*
*Сезнең тояк эзләре!*
**Кушымта:**
*Әй, атларым,*
*малкайларым!*
*Акыллы, матурларым!*
*Бар телләрдә яңгырардай*
*Сез бит горур җырларым!*
*Сез бит үлмәс җырларым!*

### *Мәхәббәт кабызган утлар*

*Мәхәббәтеңне табуы -*
*Зур бәхеттер, мөгаен.*
*Аннан аны солдат кебек*
*Саклау кирәк көн саен.*
**Кушымта:**
*Әй көчле соң*
*мәхәббәтләр,*
*Әй көчле соң сөюләр.*
*Шуңадыр да сөюләрне*
*Көюләргә тиңлиләр.*

*Гомерлек ярың табу да,*
*Саклавы да бик кыйбат.*
*Шуңа ирешсә бәхетле*
*Һәр хатын-кыз, һәр ир-ат.*
**Кушымта:**
*Әй көчле соң*
*мәхәббәтләр,*
*Әй көчле соң сөюләр.*
*Шуңадыр да сөюләрне*
*Көюләргә тиңлиләр.*

*Мәхәббәт кабызган утлар*
*Яшеннеке түгел лә.*
*Аның яктысы, җылысы*
*Җитә бөтен гомергә.*
**Кушымта:**
*Әй көчле соң*
*мәхәббәтләр,*
*Әй көчле соң сөюләр.*
*Шуңадыр да сөюләрне*
*Көюләргә тиңлиләр.*

# Социаль - мәдәни үзәк гөрли

Кирюшкино авылы культура йортында даими рәвештә төрле мавыктыргыч чаралар оештырылып килә. Китапханә һәм культура хезмәткәрләре җыелы мөнәсәбәттә булып, бергәләп әлеге чараларны үткәрәләр.

Ватанны саклаучылар көненә яшь буынны патриотик рухта тәрбияләү, спортка кызыксыну уяту максаты белән «Кайда хәтер,шунда яшь тамчысы» дип исемләнгән зур спорт чарасы оештырылды. Тантананы мәдәният йорты җитәкчесе Илмира Хамзина һәм китапханәче Лилия Абдуллина алып бардылар. Бу көнне ир - егетләр адресына иң матур теләкләр яңгырады.

Кирюшкино авылыннан Советлар Союзы Герое Мәхмүт Илачевич Аюпов та искә алынды. Аның тормыш юлы, сугышта күрсәткән батырлыгы турында сөйләнде. Яшь буынга бай тарихыбызны онытмаска, киләчәктә Герой-якташларыбыз үрнәгендә Ватанның лаеклы уллары һәм кызлары булырга дигән теләк тә әйтелде.

Спорт ярышлары бәйрәмне тагын да җанландырды. Балалар зур активлык белән биредә катнашып, файдалы ял иттеләр, сәламәтлекләрен ныгыттылар.

7 мартта, авыл китапханәсендә, Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан "Ана-бөек исем" дигән баш астында күп балалы әниләр катнашында матур очрашу үтте.

Авыл администраторы Р.Н. Абушаев кунакларны яз һәм хатын-кызлар бәйрәмнәре белән котлап, изге теләкләрен җиткерде, хатын-кызның матурлыгы, гүзәллеге, уңганлыгы, сабырлыгы турында да ассызыклап, әниләргә рәхмәтләр әйтте.

Кунаклар гаиләдә хатын-кызның роле, аның төп бурычлары, балага дөрес тәрбия бирү дигән темаларга әңгәмә кордылар, фикер алыштылар, тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

Ә инде культура хезмәткәрләренең музыкаль чыгышлары бәйрәмгә ямь өстәде. Очрашу һәр катнашучы күңелендә уңай тәэсирләр генә калдырды. Әлеге чараны оештыручылар адресына да рәхмәт сүзләре әйтелде.

**Әлфия ЯФАРОВА.**

# Күңелле кичә

Әни – шушы сүз өч хәрефтән генә торса да , мәгънәсе нинди зур аның. Әни - ул бердәнбер иң кадерле һәм иң якын кеше. Әни - ул балага җан өреп, аның күзләрен дөньяга ачучы. Әни – ул ярдәмче дә, киңәшче дә, авыр минутларда коткаручы да.

Нәкъ менә шундый изге сыйфатларга хас булган әниләр, әбиләр белән Югары Терешка авылының мәдәният йортында 8 Март Халыкара хатын-кызлар көне булып узды. Аларны авылның мәдәният хезмәткәрләре Рәшидә Биккиняева, Гөлнара Мустафина, Мәрьям Рамазанова тантаналы төстә каршы алдылар.

Югары Терешка авылында ихтирамга лаеклы, күп балалар тәрбияләгән әниләр бихисап. Авылыбыздан чыккан танылган шәхесләрне шушы тырыш, гади авыл хатын - кызлары тәрбияләгән һәм бүген дә үстереп яшиләр. Аларга таянып, өлге була беләләр. Әлеге аналарга хөрмәт күрсәтелүгә без бик шат.

Без авыл хатын-кызлары аларның кунакчыл булуына нык куандык һәм кайнар чәй өстәлләре артына утырдык. Түгәрәк өстәл артында тәмле ризыклар белән сыйланып бәйрәмебез бик күңелле узды. Кичәне алып баручы Гөлнара Мустафина үзенең ягымлы сүзләре белән һәммәбезнең күңелләрен җылытып, һәбер хатын-кыз турында матур итеп сөйләде. Мәдәният хезмәткәрләребез безнең игътибарга җырлар, шигырьләр тәкъдим итеп, йөзләребезне яктыртып җибәрделәр. Залда биюләр дә башкарылды, төрле конкурс уеннары да булды.

Шушы бәйрәмне оештырган өчен без Югары Терешка авыл мәдәният хезмәткәрләренә олы рәхмәтләребезне җиткерәбез һәм киләчәк тормышларында, эшләрендә зур уңышлар, гаиләләрендә тынычлык, байлык, исәнлек-саулык теләп калабыз.

**Югары Терешка авылының хатын-кызлары.**

Сәламәтлек

# 24 март – Бөтендөнья туберкулезга каршы көрәш көне



Шул уңайдан бу авыру турында кайбер фактларны тәкъдим итәбез:

– 1882 елның 24 мартында немец галиме Роберт Кох туберкулез авыруын тудыручы микробны ачыклый һәм шушы көннән башлап авыруны дәвалап була башлый. Галим хөрмәтенә бу микробны Кох таякчыгы дип йөртә башлыйлар;

– 1997 елдан башлап Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО) 24 мартны Бөтендөнья туберкулезга каршы көрәш көне итеп игълан итте. Ел саен бу көндә күп төрле чаралар үткәрелә башлады. Бу чаралар авыруны кисәтүне, вакытында диагноз куюны һәм туберкулез белән авыручыларның үлемен киметүне күздә тота;

– туберкулез авыруы меңнәрчә ел элек барлыкка килгән моңа дәлил булып Перуда табылган мумиедә туберкулез таякчыгы табылу тора;

– БМО саннарына килсәк, дөньядагы бар халыкның өчтән бере бу таякчыкның йөртә, әмма бик азы гына авырып китә.

– иммун системасы какшау булган кешеләр тизрәк туберкулезга бирешә. ВИЧ йөртүчеләр 20-30 тапкыр күбрәк туберкулез белән авырый. Яшәү рәвешеннәндә күп тора, 95% үлем яшәү рәвеше түбән булган илләрдә күзәтелә;

– соңгы елларда Кох таякчыкларының бик күп үзгәргән генетик линияләрен таптылар, ягъни меңнәрчә ел дәвамында барган эволюция таякчыкны үзгәрергә «өйрәткән»;

– узган гасырда табиблар: яхшы туклану, ял, саф һава, кояш тәкъдим итсә,безнең чорда авыруны җиңәр өчен «учлап» дару эчәргә кирәк. Кох таякчыгы үзгәрә, дәвалауга авыр бирешә. Дәвалану чоры 2 елга кадәр сузылырга мөмкин;

– туберкулез күбрәк үпкә, бөер, бавыр, сөякләрне зарарлый;

– галимнәрнең яңа өйрәнүләре туберкулезны кешегә сыерлардан күчкән дип түгел, ә киресенчә, кешеләр сыерларны зарарлаган дигән фаразлар да әйтә;

– беренче вакцина кешеләргә 1921 елда кулланыла башлый. Ел саен аны Жир шарында 100 млн. бала ала һәм бу прививка күп илләрнең милли календарена кертелгән, ягъни мәҗбүри. БЦЖ вакцинасы кешене туберкулезга каршы тота;

– туберкулез авыруын вакытында ачыклау йөзеннән, балаларга Манту пробасы куела, ә зурлар ким дигәндә 2 елга бер тапкыр флюорография үтәргә тиеш. Хроник авыру белән исәптә торучылар һәм эш урынында таләп ителгәннәр флюорографияне ел саен үтә. Бу тикшеренүләр табиблар өчен түгел, ә бәлки үзебезнең сәламәтлек өчен кирәк.

## “Синий кит” игра - группа смерти. Что это за игра?

Сотрудники организации зафиксировали всплеск в январе 2017 года. По обращению РОЦИТ 6 февраля администрация «ВКонтакте» заблокировала и удалила хештеги суицидных пабликов. Однако в настоящее время они активно появляются под фотографиями в Instagram. Как сообщают в РОЦИТ, было опубликовано более 45 тыс. подобных «опасных» записей.

По данным организации, используются такие отметки, как #кит, #тихий, #синий, #китом, #жду, #хочу, #разбуди #тихийднм и другие. Отмечается, что в теге «тихийднм» использована «н» казахского алфавита.

Посты, которые сопровождают эти хештеги, раскрывают условия и результат игры и также объясняют, почему дети должны пойти на самоубийство, предполагают в организации. В частности, специалисты обнаружили фотографии рук, на которых нацарапан синий кит как первый этап игры.

Представитель Instagram заявил, что компания не приемлет контент, «который побуждает пользователей Instagram к суициду или нанесению себе увечья». «Сейчас мы внимательно изучаем хештеги и аккаунты по этой теме и предпримем соответствующие меры по удалению контента, который нарушает правила нашего сообщества»,— заявил он. По словам представителя сети, недавно Instagram обновил инструменты по поддержке людей, которые переживают тяжелые времена и рассказывают об этом в Сети: «Друзья и близкие, которые заметили посты такого характера, могут найти в Instagram список специальных организаций, которые смогут помочь в сложившейся ситуации».

Советую родителям обратить внимание на поведение своих детей и уделять им внимание.

В ноябре 2016 года по делу о «группах смерти» во «ВКонтакте» арестовали одного из организаторов таких сообществ Филиппа Будейкина, известного в сети как Филипп Лис. Его обвинили в доведении подростков до самоубийства. Следственные органы установили, что через паблики молодой человек подстрекал подростков к суициду с помощью игры. По данным следователей, действия Лиса повлияли на решение 15 подростков совершить самоубийство, еще пятеро находились в зоне риска, но им удалось избежать смерти.

О «группах смерти» «ВКонтакте» было известно и раньше, говорит пресс-секретарь социальной сети Евгений Красников. По его словам, такие закрытые группы были популярны еще в «Живом журнале», после чего ввиду большей аудитории группы мигрировали в сеть «ВКонтакте». «Текст» Новой газеты» не открыл компании глаза на проблему, но помог бороться с этим явлением, потому что стали известны конкретные хештеги, сообщества и пользователи», констатирует он. Сейчас нежелательный контент блокируется по жалобам пользователей и Роскомнадзора, а также по результатам собственного мониторинга «ВКонтакте».

Представитель соцсети отмечает, что компания тщательно подходит к блокировкам и старается отделять действительно опасные группы от сообществ, к примеру, готической направленности. Кроме того, соцсеть привлекает психологов «Твоей территории» для поддержки подростков, находящихся в критической психологической ситуации.

**Юлия УСМАНОВА, Инспектор ПДН МО МВД “Павловский”.**

## Как правильно выбрать семена для посева



Начинается пора закупок семян для посева рассады. На рынке семян появляется множество новых сортов сельскохозяйственных культур. Все магазины семян буквально ломятся от их изобилия. Но вместо посевного материала жители часто остаются только с красочным пакетиком в память о покупке.

Садоводы и огородники часто жалуются на качество своего урожая. Как правило, причина этого – некачественные семена.

Опыт контрольно-надзорной деятельности показывает, что в розничной торговле зачастую реализуются семена, не включенные в Государственный реестр селекционных достижений, с истекшими сроками действия документов об их качестве, с истекшими сроками реализации, либо вообще без документов.

Следует заострить внимание на выборе покупателями качественного семенного материала. **Чтобы застраховаться от возможных неприятностей, следует помнить:**

• Согласно законодательству, допускается реализация семян сортов, включенных в Государственный реестр селекционных достижений, и осуществляется при наличии документа, удостоверяющего их сортовые и посевные качества, и фитосанитарного сертификата.

На пакетиках с семенами должна содержаться обязательная информация:

- название культуры, ее сорта;
- номер партии;
- масса или количество семян в пакетике;
- обозначение ГОСТа на сортовые и посевные качества;
- наименование, адрес и телефон фирмы-продавца;
- срок реализации с указанием числа, месяца и года.

Вниманию покупателей семян! У продавцов, торгующих пакетированными семенами овощных и цветочных культур, в наличии должны быть свидетельства на семена, в которых указываются всхожесть данных партий семян и срок действия документа. Если срок действия документа на момент реализации истек, это означает, что семена реализуются без документов подтверждающих посевные качества.

Для информации: в 2016 году на территории Ульяновской области при реализации пакетированных семян овощных и цветочных культур выявлены следующие нарушения:

- 24 нарушения, при реализации семян сорта которых не включены в Государственный реестр селекционных достижений, допущенных к использованию;
- 47 нарушений - при реализации семян и посадочного материала без документов, подтверждающих сортовые и посевные качества. Вышеуказанные партии семян выведены из оборота.

При возникновении сомнений в подлинности семенного материала просим Вас обращаться в отдел надзора в области карантина растений, за качеством зерна и семенного контроля Управления Россельхозназора по Чувашской Республике и Ульяновской области **по телефонам: г. Ульяновск 8(8422) 41-02-81; г. Чебоксары 8 (8352) 54-55-66.**

# Юбилееӊ котлы булсын!



Югары Терешка авылында гомер кичерүче Румия Адельшовна Хамзина 20 март көнне үзенең истәлекле 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Румия Адельшовна – искиткеч киң күңелле, тырыш, хезмәт яратучан, һәркем тарафыннан хөрмәт ителүче кеше. Ул үз һөнәренә гашыйк, бер көнен дә үзенең укучыларыннан башка күз алдына китермәгән, бөтен гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган укытучы. Истәлекле юбилее уңаеннан коллегабызның тормыш биографиясе белән таныштырсак, бик урынлы булыр.

Румия Адельшовна 1962 елның 20 мартында Иске Атлаш авылында 7 балалы үрнәк гаиләдә дөньяга килә. Кечкенә вакытыннан гади авыл балалары кебек әти-әнисенә йорт һәм хуҗалык эшләрендә ярдәм итеп үсә. Авыл мәктәбендә 10 сыйныфны тәмамлый һәм 1979 елда Ульяновск педагогия институтының математика һәм физика факультетына укырга керә. 1984 елда әлеге уку йортын уңышлы гына тәмамлап кайткан яшь укытучыны Югары Терешка авылы мәктәбенә математика фәнен укытырга җибәрәләр.

2001- 2006 елларда Румия Адельшовна мәктәптә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып хезмәт итә. Үзенең вазифаларын ул бар тырышлыгын куеп намус белән башкара. Даими рәвештә төрле тематик кичәләр һәм мавыктыргыч чаралар үткәрә.

Румия Адельшовна дәресләрендә һәрвакыт информацион - технологик чараларны киң кулланa, белемен үстерү өстендә бертуктаусыз эш алып бара. Аның дәресләрендә балалар зур активлык, тырышлык белән укыйлар. Румия Адельшовнага эш методикасы, балаларны яратуы, укучыларының сәләтләрен ачыкларга һәм үстерергә ярдәм итә. Аның укучылары математика фәненнән район, региональ һәм бөтенроссия дистанцион конкурсларында һәм дәүләт имтиханнарын тапшырганда зур уңышларга ирешәләр. Румия Адельшовна 8-9 нчы класс укучыларының сыйныф җитәкчесе дә. Ачык йөзле, йомшак сүзле укытучы үзенең вазифаларын һәрвакыт ихлас күңеле белән башкара. Коллегалары, ата - аналар белән дә гел яхшы мөнәсәбәттә яши.

Менә шулай, тормыш мәшәкатьләренә күмелеп, Румия Адельшовна гомеренең 33 елын укытучы һөнәренә багышлады һәм хезмәтен бүген дә зур тырышлык белән дәвам итә. Аның намус хезмәте хөкүмәт тарафыннан да күптәрле Почет грамоталары, Россия мәгариф Министрлыгы исеменнән Рәхмәт хаты һәм Хезмәт ветераны исеме белән югары бәяләнде.

Румия Адельшовна тәҗрибәле укытучы гына түгел, тормыш иптәшенә угнан һәм булдыклы хатын да, иң ягымлы әни дә, оныкларына яхшы әби дә. Авылның акыллы, тыйнак, сабыр холыклы егете Камил Сафа улы Хамзин белән тату, үрнәк тормыш корып яшәүләренә дә менә 32 ел үтеп киткән. Ике балалары да үсеп җиткән. Улары Марсель һәм кызлары Ләйсән үз гаиләләрен корып, Ульяновск шәһәрендә яшиләр. Әти – әниләренә ике онык та бүләк иттеләр. Хөрмәтле коллегабызны матур юбилее уңаеннан чын күңелдән тәбрик итәбез. Аңа исәнлек-саулык, бәхетле тыныч тормыш туганнарының, укучыларының, авыл халкының ихтирамын күреп, гел куаныч һәм шатлыкларга күмелеп яшәвен генә телибез.

*Юбилееӊ котлы булсын,*
*Бәхет алып алып килсен*
*һәр көнең.*
*Гомер үтә диеп син*
*сурелмә.*
*Көяшныкы булсын*
*гомерең.*

**Аделия АВВӘСОВА,**
**Югары Терешка**
**төп мәктәбе**
**укытучысы.**

## Истәлекле вакыйга

# Кырым – безнең йөрәктә!

18 мартта Россиянең барлык төбәкләрендә, шул исәптән Иске Кулаткы районында да Кырымның Россиягә кушылуына 3 ел тулуга багышланган “Севастополь. Кырым. Россия – без бергә” дигән баш астында митинглар үтте.

Бу көнне “Кырым – наш” скверы янына төрле оешмалар коллективлары, мәктәп укучылары, студентлар, әлеге истәлекле вакыйгага битараф булмаучы искекулаткылылар җыелдылар.

Митингта чыгыш ясаучылар район администрациясе Башлыгы И. А. Аблязов, Иске Кулаткы тарих һәм крайны өйрәнү музее Р. М. Байбикова, “Бердәм Россия” партиясенең урындагы башкарма комитеты җитәкчесе Л. Р. Амирова райондашларны әлеге истәлекле дата белән тәбрикләп, тарихи тамырлары, мәдәни мирaслары, традицияләре белән аерылгысыз булган Кырым белән Россиянең кушылуының мөһимлеген билгеләп үттеләр. Шушы өч елда Кырымның икътисади үсешен ассызыкладылар.

Ә инде “Моң дулкыны” триосының, ветераннар хорының, Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбе укытучысы В. И. Тимушеваның, дәүләт механика-технология студентларының музыкаль чыгышлары митингка бәйрәм кәефе өстәде.

**Әлфия ЯФАРОВА.**



# Фәнгә уңышлы адымнар



Мәктәп эшчәнлегенең төп максаты: балаларга ныклы белем һәм тәрбия бирү, аларның сәләтләрен үстерү. Шуңа күрә хәзерге вакытта укучылар педагоглар ярдәмендә үзләрен камилләштереп, төрле эзләнүләр алып баралар, фәнни-тикшеренүләр, эксперементаль эшләр оештырып, белемнәрен камилләштерәләр.

Күптән түгел генә Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбе укучылары Зеленодольск шәһәрендә үткән “РФнең дәүләт телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү” муниципаль программаны тормышка ашыру кысаларында Каюм Насыйри исемендәге XV нче Халыкара яшьләрнең фәнни-тикшеренү конференциясендә катнаштылар.

Конференциянең төп максаты: талантлы, сәләтле яшьләрне эзләп табу, аларның интеллектуаль мөмкинлекләрен үстерү өчен шартлар тудыру, мәктәп укучыларын тикшеренү эшләренә җәлеп итү, милли культураның гореф-гадәтләренә, рухи кыйммәтләренә кызыксыну уяту.

Әлеге конференциягә төрле регионнардан, хәттә чит илләрдән: Япониядән, Төркиядән, Кытайдан, Казахстаннан, Латвиядән катнашучылар килгән иде. Безнең Иске Кулаткы районының данын Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбенең IX-XI сыйныфлардан тугыз укучы ун проект белән чыгыш ясады.

IX “А” сыйныфтан Алсу Усманова «Измерение времени реакции человека при помощи линейки» (җитәкчесе Р.З. Халикова), X сыйныфтан Мәрьям Амирова “СМС – друг или враг” (җитәкчесе Г.Р. Усманова), IX“А” сыйныфтан Ильяс Курамшин «История повторяется» (җитәкчесе Н.А. Бадаева), XI “А” сыйныфтан Мәрьям Абдуллина “Усомнившийся Платонов” (җитәкчесе Г.Р. Курамшина) тикшеренү эшләре белән беренче урыннарга һәм медальләргә ия булдылар.

X сыйныфтан Диляра Алтынбаева “Мир предметов в поэзии Осипа Мандельштама» (җитәкчесе Н.А. Байбулатова), “Только в чистоте мира» (җитәкчесе Ф.Р. Алимова) һәм IX“А” сыйныфтан Марсель Юмангулов “Исследование влияния щелочных батареек на здоровье человека и окружающую среду на пример Старокулаткинского района” (җитәкчесе Р.Р. Аделова) икенче урыннар яуладылар.

X сыйныф укучысы Илгиз Усманов “Математические знания в различных способах посадки картофеля (җитәкчесе Г.А. Ахметова), XI “А”сыйныфтан Алсу Узбекова “Использование матриц для решения экономических задач» (җитәкчесе Р.А.Умәрова) һәм IX “А”сыйныфтан Надежда Решетникова “Мобильная зависимость» (җитәкчесе Р.К. Биккулова) өченче урыннарга ирештеләр.

Конференциядә җиңүчеләр Татарстан Республикасының мәгариф Министрлыгының һәм Казан Федераль университетының Дипломнары һәм медальләре белән бүләкләнделәр. Жюри әгъзалары Татарстан Республикасының югары уку йортлары педагоглары иделәр. Алар катнашучыларны төрле критерияләр буенча бәяделәр.

Без дә районыбызның йөзен югары дәрәҗәдә күрсәтүче тырыш, сәләтле укучыларны лаеклы җиңүләре белән котлыйбыз һәм укуларында зур уңышлар, куйган максатларына ирешүләрен теләп калабыз. Аларны җитәкләүче, ярдәм итүче укытучыларга да тирән ихтирамыбызны һәм рәхмәтебезне белдерәбез.

**Ә. ДАВЫДОВА.**

# ÊÖÒÅÏ ÓÇÃÀÍ ÃÎÌÅÐ

## *Повесть*

**Зифа Кадырова**




- Әйе, - диде Рушания чак кына ишетелерлек итеп. - Син шундый матур бүген, киемең бик тә килешә. Рушания хәлсез бармаклары белән аның җиңеннән сыйпап куйды. Шундый чибәр ир-егет белән култыклашып үтәргә иде, бөтен хатын-кыз көнләшеп үләр иде.

- Инәй, укы догаңны, әйт, күкләр ишетсен. Асылгәрәй хатыны Рушания диген, инәй, кычкырып укы, минем дә өйләнеп үләсем килә. Асылгәрәй балачактагы кебек Фатыйма инәйнең итәгенә ябышып елады.

- Балам, ни эшләвегез бу?

- Асылгәрәй, - дип Рушания үзенә чакырды. Инде ябыгып, бәләкәй генә калган Рушанияне мендәре белән бергә кочаклады. - Мин дә сине яратам, Асылгәрәй. Әни, миңа салкын, бик өшим. Фатыйма инәй өстендәге мамык шәлен аның өстенә китереп япты. Рушания аның кулыннан тотты. - Әни, кичер безне, сине ташлап китәбез.

Фатыйма инәй көчкә кычкырып елаудан тыелып утырды, балалар алдында ул һәрвакыт көчле булып күренергә өйрәнгән. Рушания кинәт артка тартылды да, күзләрен зур итеп ачты. Аяк очында утырган Асылгәрәйгә Рушания өстеннән ак яктылык күтәрелгәндәй булды.

- Инәй, - диде ул куркып, бер түшәмгә, бер Рушаниягә карап. Фатыйма инәй йөрәген тотып урындыкка утырды.

Түшәмгә текәлгән олы күрән күзләр җанын озатып карап калды. Тәрәзәдә нәрсәдер шыпыр-шыпыр килгәнгә борылып карадылар, анда бер ак күбәләк тышка очып чыга алмый бәргәләнә иде. Идәнгә нәрсәдер челтерәп төште, алар сискәнеп киттеләр. Алтын йөзек, әйләнеп- әйләнеп, Асылгәрәйнең аяк астына килеп ятты. Асылгәрәй әле кулына, әле идәндәге балдакка карады. Аннан яшьле күзләрен Фатыйма инәйгә күтәрде.

- Эх, - диде әрнешеп. - Ул миннән тагын китте...

Рушания җәй азагы, көз башында үлде.

Рушания бу дөньядан соңгы юлга озаткан әнисенә, бөтен авыртуларын, бар газапларын үзенә алырга әзер торган Асылгәрәйгә мең-мең рәхмәтле иде. Патшабикәдәй горур, гүзәл элекке Рушаниядән калган шәүләне, аның ябыгуын ире, балалары күрмәде. Бөтен хосрәт-газапны әнисе белән Асылгәрәй үз өсләренә алды. Сөекле кешесенең шәм урынына янып бетеп баруын күрү Асылгәрәйгә җиңел түгел иде. Ул үз авыруын онытып, сүнеп барган күрән күзләрдән сәгатьләр буе күзен алмады. Бөтен курыкканы, йөрәге күтәрә алмыйча, аннан алда китеп бару иде. Рушания аңа икесе арасындагы мөнәсәбәтләрне үзенчә аңлатырга тырышты: ул аның өчен бик кадерле кеше иде аларның балалыгы бергә бәйләнгән, бер-берсенә карата икесе генә тоя торган миһербанлылык, уртак авыру-газап һәм шуның белән бергә, ир белән хатын арасында була торган тойгылардан, мәхәббәттән дә өстен тагын әллә ниләр бәйли иде аларны. Әйе, алар ир белән хатын була алмадылар, тик шулай да, әгәр теге дөньяда икенче тормыш булса, һичшиксез, бергә булачакбыз, дигән өметтә иде алар. Якты дөнья белән хушлашуның ачысын, соңгы сулышын күрүне авыр кичерделәр.

Асылгәрәй, кагыйдәләрне бозып булса да, Рушанияне читтә аерылып торган куш каен янына күмдерде, өч көннән Рушаниянең иң матур фотосы белән кара мәрмәр кабер ташы китереп урнаштырды. Икенчесен, үзенә дигәнен өй астындагы подвалга төшереп яшерде. Мәхмүткә генә әйтте: «Мин үлсәм, шуны куярсыз». Асылгәрәй көннәр буе зиратта югалып йөрде. Көз соңлады, һаман җылы, күбәләкләр дә һаман очалар, алар әллә ничәү.

- Рушания, син дә шундасыңдырла, кайсысы син, мин ничек табармын соң сине?

Инзир буенда төннәр буена яңа җыр яңгырады:

*Ташлап киттең мине,*
*Моңсулатып җирне,*
*Мине үзең белән алмадың.*
*Яшәр бу, дип уйладың.*
*Үлгәннәрнең җаны күбәләк,*
*Күбәләкләр оча зиратта.*
*Кайсысы, бәгърем, син икән,*
*Тагын югалтсам, нишлим икән?*

Бер ай дигәндә Асылгәрәйнең гармуны да тынды. Мәхмүт ару-талу белми елга буеннан йөгерә- йөгерә эзләде. Елга буеннан тапмагач, зиратка йөгерде, үзе вакыт-вакыт, абый-абый дип кычкырды. Көзнең иң матур чагы, әбиләр чуагы иде. Акрын гына сары яфраклар коела. Асылгәрәй куш каенга аркасын терәп утырган, әйтерсең, уйланып утырып йокыга киткән, эшләпәсен күзенә төшергән. Көзге кояшның соңгы нурлары учындагы алтын балдакка сузылган. Мәхмүт аның каршысына утырды.

- Әйдә кайтыйк, әни көтә.

Асылгәрәй эндәшмәде. Мәхмүт тә аркасын каенга терәде дә, үзалдына сөйләнеп утыра бирде. Кичкә чаклы утырды. Аларны инде Маһинурның балалары да эзләп чыкканнар иде. Асылгәрәй, ахрысы, таңда ук җан биргән иде. Ике бертөсле кабер ташын беррәттән куйгач, укып еладылар («Рушаниям бәгърем, синнән башка яшәү - яшәү түгел икән» диелгән иде). Фатыйма апасын тотып торган Маһинур, апасына карап:

- Алла ярдәм бирсен үзеңә, ничекләр чыдыйсыңдыр, - диде күз яшьләрен сөртеп.

- Әрем сулары эчеп, - диде акрын гына Фатыйма абыстай.

***

Александр Ивановичның баласы туды. Картайганда туган бала бик тансык, диләр. Ул үзенчә бик бәхетле иде, Мариночкасы ул бүләк итте. Алар менә елга якын инде Франциядә яшиләр. Үзләренә бер аерым өй арендага алып яшәп яткан көннәре иде. Малай табып биргән өчен Маринага миллион сумлык муенса алып бирде. Яшь хатын Рушания белән чагыштырырлык түгел иде, капризы да, теләкләре дә бик зурдан. Александр Иванович башта акчаны чамасыз түкте, тик соңгы вакытта кесә төбе саегуын тоеп, курка калды. Җитмәсә, бер айлык балалары чирләп китеп, больницага эләктеләр. Балага кан салырга кирәк булды. Әти кеше үз канын салуны таләп итте, тик табиб:

- Сезнең канны сала алмыйбыз, сез аның атасы түгел, - дип аңлатты. Александр Иванович бер агарды, бер күгәрде, акча түләп, кабат анализ ясатты. «Юк», диделәр. Бер минут эчендә башыннан бөтен гомере үтте. Ул үзен мөгезле ат итеп хис итте. Раясы белән яшәп, моның турында уйлап та караганы булмады, Раясы өчен ул бит Алла иде. Бермәлгә йөрәге кысып алды. Бала әзрәк рәтләнгәч, ул Маринага: «Җыен, Россияга кайтабыз»,- диде.

- Мин бүтән Россияга кайтмыйм.

- Алайса, кал, мин синең белән бүтән яшәмим.

Ул үзенең нинди капкынга эләккәнен яхшы аңлады, ярый әле Раясы белән законлы аерылмаган, монысына өйләнмәгән иде. - Ул үзе кебек байларга куелган тозак турында юксаң тыңлап-ишетеп кенә яши иде, менә килеп капты да инде туймас яшь җилбәзәккә.

- Син балага алимент түләргә тиешсең.

- Юк шул инде, кемнән тапкансың - шул түләсен, минем кулда документ, бала минеке түгел.

Марина да агарып катты, ул да аңлый монда калса, бернәрсәсез урамда каласын. Үз өендә ничек тә җайлар, карт беркая да бармас, кире кайтыр. Маринаның унбиш-егерме чемоданы җыелды. Александр Иванович көчкә Чаллыга тике җитте, ул беркайчан булмаганча өенә ашкынды. Ул юл буе башын аска иеп, уйланып кайтты, әйтерсең, күзен каплап юрганнарны ачып җибәргәннәр. Нишләде? Аяк астында җәймә булып ятармын, кичер, Раечка, диярмен, балалардан гафу үтенермен. Я Ходаем, нишләдем мин, гомер җыйган акчаларны туздырдым. Акчасы чукынсын, анысы табылыр, акча безне түгел, без акчаны эшлибез. Раечка гына кичерсен.

Ул Раясын күзалдына китереп, үлеп сагынганын аңлады. Раям , кичер мине, мин беркайчан беркая китмәячәкмен диярмен». Чемоданнар төялгән газель Мариналар ишек төбенә килеп туктау белән, Александр Иванович сикереп төште дә, тукталышка барып такси алып урмандагы өенә кайтып китте. Капка төбенә килеп җитүгә, өенең тәрәзәләренә үрелеп карады. Бер җирдә дә ут юк. Рая үзе генәдер, я мунчададыр. Капкада каршындагы кеше сакчы булып чыкты, кертми йөдәтте. Сакчы начальнигына шалтыраткач кына ачты.

- Өйдә кем бар?

- Беркем дә юк, мин белмим, каялардыр.

Көзнең ямьле мәле, тышта да җылы, кич, кояш баеп килә. Иң беренче булып бакчага керде, керде дә хәйран калды: җир тулы коелган алмалар, чәчкәләр дә утыртылмаган, чүп уталмаган. Бу ни хәл? Александр Иванович арлы-бирле йөрде, өстен салып атты да кәрзин алып, аяк астында аунап яткан алмаларны җыя башлады. Рая элек агачтан гына өзеп,алмаларны, капларга тутыра торган иде. Бу артыгын кая куя иде икән соң? Ул Рая белән утыра торган кәнәфигә килеп утырды, эй Раечка, тизрәк кайт кына, сөйләшербез. Ул Франциягә барып төшү белән кесә телефонын югалтты, кая булды - һич хәтерләми. Башта улына үпкәләп, мине аңламыйсың, бу мәхәббәт, дип талашты. Улы аның күзен ачтырырга ничек кенә тырышмасын, ул, әйтерсең, сихерләнгән, ана эткә тап булган ата эт кебек, Марина артыннан чапты. Чит илгә чыккач, иркенлеккә чыгуларына сөенделәр. Җенси азгынлык идеме бу - көн-төн урыннан тормаган көннәре булды, эш турында да уйламады. Шундый авырлык белән нигез салган сәүдәсен дә онытты, бернинди тәҗрибәсе булмаган улына өйдә дә чыгып китте. Рая, ах, Рая... Үзенең ничек качып чыгып баруы исенә төште, битенә ут капты, оят иде, ничек күзләренә карар... Өйгә кереп олы зал уртасына басты, бу вакытта тәмле ризык исе тарала торган иде, җыелып бер өстәл артында утырулар нинди бәхет булган. Йокы бүлмәсенә күтәрелде, шкафларны ачып карады - бар нәрсә үз урынында. Рушания йоклый торган мендәрне күтәреп иснәп карады. Аларның тумба өстендә икесе генә төшкән фотолары тора иде - күренми, кая икән дип, тартмаларын ачып карады. Бу ни дип, бер төргәк тартып чыгарды да башта куркып атып җибәрде, аннан актарып карады. Бу - Раяның үрелгән чәч толымы иде. Александр Иванович урынынннан торып басты. «Рая, нишләдең син? - Әйтерсең чәч толымы түгел, Рая үзе ята. - Ничек кулың күтәрелде, ни хакың бар иде миннән сорамыйча кисәргә?» Ул ишекле-түрле бәргәләнде, аска төшеп чәй куйды, тик тынычлана алмады. «Бөдрәләтеп тә кайт, йолкып бетерәм». Йортка машина кайтып кергәне ишетелде. Ул түзмәде, каршы чыкты. Машинадан Алеся белән бер егет чыкты, аннан улы. Алар аңа ят кеше күргән кебек карап тордылар. Тик кызы яныннан берсүзсез үтеп китте, исәнме, әти, димәде. Игорь башта берсүзсез аяк астына карап торды. Сөйләшү авыр булачак иде.

- Әти, әйдә бакчага, шунда сөйләшәбез. Таныш бул - киявең.

Алар кул биреп күрештеләр. Игорь бакчада әнисе белән яратып утыра торган кәнәфи таганга таба китте, машинадан ачып бер шешә коньяк та алды. Әтисе белән ничек сүз башларга, ни дип кайткан? Игорь янына килеп утырган әтисенә стакан белән коньяк тоттырды, үзе берсүзсез эчеп тә куйды.

- Улым, син эчми идең бит. Игорь улым, әниең кая?

- Син, әти, үзең турында сөйлә, кайларда ниләр бетереп кайттың, бөтенләйгәме?

- Мин, улым, синең алдыңда да, әниең алдында да гаепле. Син хаклы булгансың, мин, улым, сездән башка, әниеңнән башка яши алмыйм, ничаклы ялгышлар ясаганымны үзем дә аңлыйм, әниең генә кичерсен иде, улым.

- Әни кичерде, әти, ул барысын да кичерде.

- Минем бер әйбергә бик ачуым килеп утыра идем. Әниеңнең шкаф тартмасыннан чәч толымы килеп чыкты, ни дигән эш ул. Яшьләр артыннан мода куамы әллә? Әтисе тагын әллә ни дип тузынды, Игорь борылып күз яшен сөртеп алды, тик әнисенең юклыгын әйтергә теле әйләнмәде.

- Әти, ник телефоныңны алмадың, мин сиңа күпме шалтыраттым, син бик тә кирәк идең бит, эх, әти...

- Мин аны самолеттан төшүгә югалттым, әллә өйдә калдымы дип тә уйладым. Шуннан яңасын алдым.

- Нишләп алайса бөтен язганны кабул итмәдең? Мин яздым бит сиңа кайт дип, ә син, минем икенче гаиләм бар, борчыма, дип җавап җибәрдең.

- Кем, минме?

- Алайса, яшь хатыныңнан сора, анда телефоның. Эх, әти, әти, әни кичерде дә ул сине, син менә кичерерсеңме үзеңне?

Игорь башын куллары белән кысты, еламаска тырышты.

- Улым, ни булды, нәрсәдер әйтергә телисең дә, әйтмисең.

Игорь йолдызлы күкләргә бакты, эчкән коньяк та ярдәм итмәде, тагын салып эчте.

- Без, әти, әнине җирләп килдек.

Ниндидер тынлык урнашты. Игорь әтисенә борылып карады, ул артына хәнҗәр кадалгандай аңа текәлеп каткан иде.

- Ни сөйлисең, балам? - диде, көчкә телен әйләндереп.

- Кичә, туган авылында. Син киткәч, ул аңына килә алмыйча бер үлгәннән калды, шунда гына мин аның рак белән чирләгәнен белдем, ул инде күптәннән чирләгән, безне жәлләп әйтмәгән.

- Син мине табарга тиеш идең, ишетәсеңме, син мине табарга тиеш идең. Әтисе калтыранып бар көченә кычкырды.

- Әни әйтергә кушмады, үзе монда, йөрәге анда булыр, кирәкми, кызганып, минем үлгәнне көтеп утырмасын, диде. Син аны бик рәнҗетеп киттең, әти.

- Рая, Раечкам минем, ничек шулай уйлый алдың? Мине кичерергә мөмкин түгел. Мин бит аның белән хушлашырга йөрәгем җитмәде, аңладым, мин хаклы түгел. Ник кирәк бу дөнья ул булмагач? Александр Иванович бөтен җаны әрнеп кычкырды. Менә кайда иде соңлап килгән үкенеч.

- Әни сиңа хат калдырган, - дип кесәсеннән хат чыгарып бирде.

Әтисе калтыранган куллары белән аны ертып, яктыга килеп укырга маташты, тик күзгә тулган яшь укырга бирмәде, ул ашыгып өйгә кереп китте. Аның язуын күрү белән елый башлады, түзә алмый арлы-бирле йөренде, аннан үзләренең йокы бүлмәсенә кереп китте.

«Сашенька, хушлашмыйча киттең, менә мин дә хушлашмыйча китәм, мин сине кичердем, син икебез өчен дә яшәргә тиеш, балаларга терәк бул. Мин ышанам синең кире кайтуыңа. Ходай безнең мәхәббәткә сынаулар үткәрде, син шул сынауны үтә алмадың. Аңларсың ялгышыңны. Сашенька, син миңа бик тә кирәк идең, бөтен теләгем - тизрәк әйләнеп кайтсаң иде, балаларга авыр булыр икебезне дә югалтсалар. Мин синең белән бик тә бәхетле булдым, син елама, син яшә. Оныклар туар, син аларны минем өчен дә сөй, ярат. Түз, бар да яхшы булыр».

Александр Иванович үзе генә белде ялгыз авырлыкны. Аны сынаулар алда көткән икән әле. Ул Рушаниянең көндәлеген табып алды. Ул укый-укый бер кызарды, бер агарды, ул үзенең хыянәтен читтән күрде, сөекле хатынын нинди газапларга салуын, аны кемгә алыштыруын аңлады. Кызганыч, Ходай аны үз гөнаһларыңда үзең газап чик дип исән калдырган. Ул көннәр буе бакчада йөрде. Тиеннәрне кул сугып күпме генә чакырса да, алар бүтән килмәделәр. Башка бәхетле бакчага күчтеләр бугай. Бакчаның һәр почмагында Рушания күренде күзенә. Александр Иванович хатынын бакчаның һәр почмагыннан эзләде, һәр сукмак аны хәтерләтте, ул көннән-көн ныграк сыгылды, чәчләре агарды, үз эченә бикләнде. Вакыт- вакыт бушлыкка: «Кичер мине, кичер, кадерлем», дип кычкырды, ялынулары җавапсыз калды. Кайчандыр ул Рушанияне ишетмәгән кебек, хәзер аны Рушания ишетмәде. Әнисенең кырыгына әбисе кайтырга кушты. Алар җыелышып авылга кайттылар. Игорь машинаны туры зиратка алып килде, әнисе кабере янында үсеп чыккан яңа каберне күреп, сискәнеп китте. Коелган сары яфракларны кара мәрмәр таш өстеннән сыпырып карады да чайкалып куйды.

- Алик абый? Юк, моның булуы мөмкин түгел.

Куш каен төбендә аерылып торган ике кабер, аларның ташлары да бертөсле. Өстенә язылган язуны укып, мәгънәсен аңларга тырыштылар. Александр Иванович шашып калгандай карап катты.

- Бу кем, бу кем, ник алар бергә? - диде калтыранып.

Игорьга да бик авыр булып китте. Бу хәлне һич башына сыйдыра алмады, алар бер елда туганнар, бер елда үлгәннәр. Ничек аңларга моны?

Фатыйма әбиләре шушы бер ай эчендә йөзе сулып, күзләренә сары сагыш сарган. Балалар әбиләрен жәлләп, яшьле күзләрен аңа төбәделәр. Фатыйма инәй алар арасында ап-ак чәчле Сашаны күреп, бик озак аңа карап торды. Аны Айбикә инәй үлгәннән бирле күргәне юк иде. Аның күзендә сагыш ярылып ята. Игорь әбисен кочаклап:

- Әбием, ник болай, без яратканнар безне ташлап китәләр?

- Асылгәрәй абыең әниеңнән башка яши алмады, китте артыннан. Саша, ачуланма, олы мәхәббәт шунда сыналадыр, күрәсең. Ул аны соңгы юлга озатты, беррәттән генә ятарга булса да хакы бардыр. Без аны җан биргән җиргә җирләдек.

Раечкасын үзеннән башка кем беләндер беррәттән күрү башка сыешлы хәл түгел иде. Сашада капма-каршы хисләр көрәште. Ул гомер буена Раечка минеке генә дип яшәде, аның күңел чисталыгында да һичкайчан шикләнмәде, ә бүген килеп кемдер берәү аның урынын алган. Менә шул мизгелдә Раечкасын югалтканын аңлады. Аның урынын башка берәү алган. Раечкасы бәлки кичергәндер дә бит, тик йөрәген башка берәүгә биреп киткән түгелме?

Фатыйма инәй Игорьны Асылгәрәй бүлмәсенә алып керде.

- Менә монда кәгазьләр калдырган, сиңа бирергә кушкан. Ул беркайчан да үзе турында сөйләмәде, үлгәнче чирле икәнен дә белмәдем. Менә киемнәре.

Игорь кәгазьләрне актара торгач, Алик абыйсының су асты көймәсендә хезмәт иткәнен, зур гына чинлы офицер булуын аңлады. Шул ук вакытта атом реакторында аварияга эләгеп, көчле нурланыш алганы ачыкланды, ул инде алты ел элек икенче группа инвалид булып чыгарылган була. Шуннан соң ул авылына кайткан. Ул кәгазьләргә, фотоларга күз салды, зур кеше булган, ә киемнәре ничек килешә. Берәү булса, мактаныр, кат-кат сөйләр иде. Юк, барысын үзе белән алып китте. Кәгазьләр арасыннан бер генә хатын-кыз фотосы чыкты, ул матур алтын рамкага алынган, ул да булса аның әнисе иде. Әбисе хаклы, олы мәхәббәт вакланмаган. Тагын бер конвертны кесәсенә бөкләп тыкты, монысын кайткач карармын дип. Игорь хәзер әтисе өчен борчылып яшәде, әтисе үз эченә бикләнде. Эшкә кайтырга да җыенмады. Алар әниләренә матур кабер ташы ясатырга биргәннәр иде, тик авылга кайтып килгәч, аны алып кайтуның кирәге калмады. Әтисе аны бакчаның бер почмагына урнаштырды да көннәр буе шуның каршысында утырды. Кайдадыр Раечкасының кем беләндер беррәттән ятуын уйлыйсы да килмәде. Ул монда, ул аныкы гына, дип, үз-үзен ышандырырга тырышты. Ул кинәт бер картка әйләнде. Игорь белән Алесяга ничек тә әтисе оештырган сәүдәне тартырга кирәк, зур гына завод хуҗасы булу бер дә җиңел түгел иде. Беркөнне аның кабинетына ярдәмчесе керде:

- Сезне анда бер кыз көтеп утыра, кабул итүегезне сорый.

- Ярый, керсен, - диде Игорь.

Кабинетка кыяр-кыймас кына какча буйлы, бик гади генә киенгән кыз килеп керде, керде дә аптырап аңа карап катты.

- Ни йомыш?

Кыз бер кулындагы кәгазьгә, бер каршысындагы егеткә карады.

- Миңа Захаров кирәк.

- Мин булам Захаров Игорь Александрович.

Кыз аның алдына конверт китереп салды. Игорь аны ачып укыды да, кызга күтәрелеп карады.

- Миңа Рушания апа калдырган иде, сезгә барырга кушкан, белмим нигә. Юк, беләм, менә бу карточканы алып килдем, - дип, кыз бик дулкынланып, аның алдына акча ала торган карточка чыгарып салды.

- Сез кайдан беләсез минем әнине?

- Алар әни белән бергә больницада яттылар. Картаны ул миңа бер ел элек китергән иде. Безгә укырга түләргә дип. Мин акчаларны җыеп тутырдым.

**Дәвамы бар.**

